ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.04.2021 М ө с л и м № 166

**«Мөслим муниципаль районы территориясендә эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд төзү турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 февралендәге 69 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законга, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законга, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законына, Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряды турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 21 гыйнварындагы 02-20-р номерлы күрсәтмәсенә туры китерү максатларында, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Мөслим муниципаль районы территориясендә эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд төзү турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 февралендәге 69 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 3, 4, 5 пунктларын түбәндәгечә бирергә:

«3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.».

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т. Демидов**